**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

24.04.2015 ел № 59/3

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 52/2 номерлы Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 52/2 номерлы Әҗмәкәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге советы карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктка:

а) 1 пунктчада:

өченче абзац өстәргә:

«мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар. Ставка бер гаражга яки салым түләүче сайлаган машина-урынга карата билгеләнә.»;

Өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга.

б) 4 пунктчада:

икенче һәм өченче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

"6) 2015 елда 1,5 процент, 2016 елда 1,8 процент, 2017 елда 2 процент һәм аннан соңгы елларда:

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ маддәсе турында 1 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектлары.»;

Түбәндәге эчтәлектәге яңа 3 пунктны өстәргә:

«3. Ике фатирлы күпфатирлы бер катлы торак йортта фатирга милек хокукына ия булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнгән суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәрберсе өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәрберсе өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пунктка ярашлы исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аның исәбеннән башка артмаска тиеш».

1.2. 3 һәм 4 пунктларны 4 һәм 5 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында «авыл җирлекләре»бүлегендә рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Фазылҗанов